**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 27 декабрь | № 1011

г. Казань

Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 ел, 6 декабрь, ПУ-1115 нче Указын алга таба тормышка ашыру, Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы министрлыкларына, дәүләт комитетларына, ведомстволарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10сына кадәр, Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе секретариатына әлеге карарда күздә тотылган чараларны тормышка ашыру турында хисап кертү;

фотога төшерү һәм видеога язып алу системаларыннан файдаланып чыгарылган административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча карарларның күчермәләрен электрон мәгълүмат таратуга тоташтыру өчен чараларны үтәүне дәвам итү.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасыннан иң актив файдаланган граждannar өчен акчалата бүләкләү тәртибен эшләргә.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә

пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 25 май, 352 нче карарына мәктәп автобуслары белән элемтә булмаганда эш-гамәлләр алгоритмын билгеләү өлешендә үзгәреш кертергә;

төбәк әһәмиятендәге массакүләм чаралар үткәрү урынына балаларның оештырылган төркемнәрен илткәндә куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча эш-гамәлләрне яраштыру һәм ведомстовара хезмәттәшлек итү өчен балаларның оешкан рәвештә юлга чыгуы турында хәбәрнамә формасын эшләргә һәм расларга;

түбәндәгеләр белән берлектә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән – 2017 елның 1 февраленә кадәр муниципаль юл фондларының 2016 елда үзләштерелми калган акчасын 2017 елда юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча чараларны үтәүгә юнәлтү буенча тәкъдим кертергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән – белем бирү оешмалары янындагы икенче дәрәҗәдәге автомобиль юллары һәм торак пунктлар урамнары тоташкан урыннарда тизлекне мәҗбүри киметү җайланмалары (ясалма тигезсезлекләр) кую буенча адреслы программаны 2017 елның 1 апреленә кадәр эшләргә һәм 2017 елда гамәлгә ашырырга һәм 2017 елның 12 сентябренә кадәр белем бирү оешмалары янында җәяүлеләр чыгу урыннарына юл тамгалары ясауны төгәлләргә;

2016 ел ахырына кадәр төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу сәбәпләрен анализларга һәм 2017 елның 1 апреленә кадәр юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны бетерү буенча чаралар исемлеген эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге идарәсе белән – кимендә айга бер тапкыр автобусларның законсыз рәвештә пассажирларны йөртү фактларын һәм пассажирларның санкцияләнмәгән утыру урыннарын бетерү буенча чаралар үткәрергә;

Горький һәм Куйбышев тимер юллары («Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиаллары) белән – тимер юл аркылы чыгу урыннарын норматив таләпләргә туры китерү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны дәвам иттерергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Казан һәм Чаллы агломерацияләре составына керә торган муниципаль районнар белән – «Имин һәм сыйфатлы юллар» өстенлекле юнәлеше кысаларында автомобиль юлларын норматив хәлгә китерүгә һәм шәһәр агломерацияләренең юл челтәрендә юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар эшләргә;

мәнфәгатьле министрлыкларга һәм ведомстволарга алардан файдалана алу мөмкинлеге торышы һәм тизлек режимын саклау турында мәгълүмат тапшырып, мәктәп автобуслары эксплуатациясенә даими нигездә мониторинг үткәрергә;

автомобиль юллары участокларын төзекләндерү яки ремонт үткәрү урыннарында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләргә һәм тормышка ашырырга;

мәктәп автобуслары маршрутлары үтә торган төбәк әһәмиятендә булган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларын норматив таләпләргә туры китерү чараларын 2017 елга юл эшләре программасы нигезендә үтәүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

2017 ел дәвамында юл-транспорт һәлакәте (урыны, зыян күргәннәр саны һ.б.) турындагы мәгълүматны оператив рәвештә җиткерү өчен ашыгыч медицина ярдәме бригадалары планшетларын гамәлгә кертерергә, шул исәптән аларны Татарстан Республикасының кичектергесез медицина хезмәтләренең санитария автомобильләрендә трекерлар сыйфатында куллану өчен;

ашыгыч медицина ярдәме станцияләре (бүлекләре) фельдшерларын «Гадәттән тыш хәлләрдә һәм башка көтелмәгән хәлләрдә зыян күргәннәргә медицина ярдәме күрсәтү» программасы буенча укытуны дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, 2017 елның 1 июленә кадәр зур габаритлы һәм авыр йөкләрне йөртүгә рөхсәтнамәләр бирүне электрон рәвештә түләү мәсьәләсен хәл итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

юл-транспортта җәрәхәтләнүне кисәтү эшләренә яшьләр оешмаларын һәм берләшмәләрен җәлеп итүне тәэмин итәргә, шул исәптән пропаганда чаралары һәм махсуслаштырылган акцияләр, семинарлар һ.б. кысаларында;

түбәндәгеләр белән берлектә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр органнары белән – 2016/2017 уку елы дәвамында белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнарны юлда имин йөрү кагыйдәләренә укыту предметына тикшерүләр үткәрергә;

яшь хәрәкәт инспекторлары отрядлары эшчәнлегенә оештыру ягыннан һәм методик ярдәм күрсәтергә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән – мәктәп автобусларын тизлеге һәм хәрәкәт маршруты, йөртүченең эш һәм ял режимы хакындагы мәгълүматны теркәүне тәэмин итүче техник тикшерүдә тоту чаралары белән җиһазландыруны дәвам итәргә;

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне гомуми белем бирү оешмаларында укуга әзерләү кысаларында беренче сыйныф укучыларын яктылык кайтару элементлары белән тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән берлектә дәүләт муниципаль спорт учреждениеләре автобусларын тизлеге һәм хәрәкәт маршруты, йөртүченең эш һәм ял режимы турындагы мәгълүматны теркәүне тәэмин итүче техник тикшерүдә тоту чаралары белән җиһазландырып бетерү буенча чаралар күрергә;

2017 елга спорт чараларының календарь планын формалаштыруны һәм 2017 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына җиткерүне тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын җәлеп итеп, кимендә ярты елга бер тапкыр юл-транспорт һәлакәтләрендә эш итү буенча тактик-махсус өйрәнүләр үткәрергә;

юл-транспорт һәлакәтләре китергән зыяннарны бетерүгә җәлеп ителә торган көчләрне һәм чараларны үз вакытында әзерлек хәленә китерү һәм оператив эш итү максатларында, Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуның оператив фаразын мәнфәгатьле министрлыкларга һәм ведомстволарга көн саен җиткерүне оештырырга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, гомуми белем бирү оешмаларында тереклек эшчәнлеге иминлеге нигезләре буенча «Тормыш иминлеге өчен юлда иминлек» дигән темага дәрес үткәрергә;

Татарстан Республикасының янгыннан коткару бүлекчәләрен техниканың заманча үрнәкләре, һәлакәттән коткару җайланмалары белән җиһазландыруны дәвам иттерергә;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасының янгыннан коткару бүлекчәләре хезмәткәрләрен «Беренчел ярдәм күрсәтү» курсы буенча укытуны үткәрергә.

8. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына өс киемнәре һәм аяк киемнәре җитештерүчеләргә яктылык кайтару элементларын куллануны киңәш итәргә.

9. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгене тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

ведомство буйсынуындагы дәүләт оешмалары (муниципаль оешмалар) тарафыннан укучыларның һәм тәрбияләнүчеләрнең муниципаль берәмлектән, Татарстан Республикасыннан һәм Россия Федерациясеннән читкә юлга чыгуын оештыруга карата таләпләрне үтәүне, шул исәптән көтелмәгән хәлләр килеп чыкканда аларны урнаштыруны һәм туклануын оештыру буенча.

10. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

2017 ел ахырына кадәр юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә хокук бозуларны билгеләгәндә фотога төшерү һәм видеога язып алу системаларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыра торган яңа технологияләрне гамәлгә кертү буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл министрлыгы белән берлектә, төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында зур габаритлы һәм авыр транспорт чаралары хәрәкәтенең автоматлаштырылган йөк һәм габарит контроле системаларын уңайлаштыру һәм кулланышка кертү буенча чаралар күрергә.

11. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына юл хәрәкәте иминлеге буенча, шул исәптән тәүлекнең караңгы

вакытында һәм күз күреме начар булганда яктылык кайтару элементларын куллану буенча социаль реклама әзерләүне һәм трансляцияләүне оештырырга.

12. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына:

махсус ут һәм тавыш сигналлары бирү өчен җайланмалар белән җиһазландырылган транспортны әзерләү һәм тәэмин итү практикасын даими тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга;

2017 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләренә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссия турындагы нигезләмәнең һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссиянең эш регламентының бертип проектларын җибәрергә;

2017 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссия утырышларын әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашырга;

түбәндәгеләр белән берлектә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән – юл-патруль хезмәте хезмәткәрләрен «Беренчел ярдәм күрсәтү» курсы буенча укытуны үткәрергә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән – Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар хакындагы мәгълүматның үз вакытында кертелүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләргә һәм 2017 елның 1 июленә кадәр гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм Татарстан Республикасы прокуратурасы белән – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасыннан иң актив файдаланган гражданнарны бүләкләү турында тәкъдимнәр кертергә;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән – гражданнарга юл хәрәкәте иминлеге торышы турында мәгълүмат җиткерүне, юл хәрәкәтендә катнашучыларда законнарга буйсынган тәртип формалаштыруны, шулай ук куркынычсызлыкны тәэмин итүнең индивидуаль чараларыннан файдалануны пропагандалауны дәвам иттерергә;

«Тереклек эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе һәм Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән – республика массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларының юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә квалификациясен күтәрүне дәвам иттерергә;

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә түбәндәгеләр тарафыннан салынган административ штрафларны түләттерүне активлаштырырга:

судлар тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.8, 12.26 статьяларында күздә тотылган административ эшләрне карап тикшерү нәтиҗәләре, бурычлыларның мөлкәтенә (транспорт чараларына) арест салу буенча;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе һәм Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге идарәсе вазыйфаи затлары тарафыннан вазыйфаи һәм юридик затларга карата;

«Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә:

I-б техник категорияле юл участокларында каршы полосага чыгу нәтиҗәсендә булган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү өчен, шулай ук җәяүлеләрнең тиешле булмаган урыннарда машиналар йөри торган өлешкә чыгуын чикләү өчен күчәр металл киртә, шулай ук җәяүлеләр чыгуын чикли торган киртәләр куюны дәвам иттерергә;

реконструкцияләү, ремонтлау һәм капиталь ремонтлау, шулай ук автомобиль юлларын төзекләндерү программалары кысаларында бер юнәлештәге ике һәм аннан күбрәк полосалы юл участокларында 5.19.1 «Җәяүлеләр чыгу урыны» дигән юл билгеләрен машиналар йөри торган өлеш өстендә куюны дәвам иттерергә;

2017 елның 1 июленә кадәр, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, федераль әһәмияттәге юлларда юл-транспорт һәлакәтләре сәбәпләрен анализларга һәм юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны бетерү буенча чаралар исемлеген эшләргә;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенә 2017 елның 30 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогы һәм 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты матчларын үткәргәндә чикләүләрне билгели торган норматив хокукый акт проектын җибәрергә;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты һәм Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчеләренә муниципаль пассажирлар транспортында һәлакәт куркынычын профилактикалау буенча, шул исәптән пассажирларның иминлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына:

бюджетларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль максатчан программалар чараларын тормышка ашыруга чыгымнарны күздә тотарга;

гомуми файдаланудагы юллар буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүләрне кертүне минимальләштерә торган ачык чаралар һәм спорт чаралары үткәрү урыннарын билгеләргә;

2017 елның 15 гыйнварына кадәр «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль максатчан программаларны, алга таба квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10сына кадәр – әлеге максатчан программаларны тормышка ашыру барышы турында мәгълүматны тапшырырга;

муниципаль берәмлекләрнең торак пунктларында юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы проектларын эшләүне дәвам иттерергә, юл билгеләрен юл хәрәкәтен оештыруның расланган проектларына туры китерү буенча чаралар оештырырга;

2017 елның беренче яртыеллыгында муниципаль комиссия утырышында юл-транспорт һәлакәтләре чыгару сәбәпләрен һәм шартларын бетерүгә юнәлдерелгән беренче чираттагы чаралар нәтиҗәләрен карап тикшерергә;

мәктәп автобуслары маршрутлары үтә торган җирле әһәмияттә булган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларын норматив таләпләргә туры китерү чараларын үтәүне тәэмин итәргә;

бюджетларда 2017 елның IV кварталына җирле әһәмияттә булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын кыш көне карап тоту буенча чараларны тормышка ашыруга чыгымнарны күздә тотарга;

2017 елның 1 мартына кадәр – җирле әһәмияттә булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының чокырларын ямау буенча агымдагы ремонтка һәм 2017 елның 15 декабренә кадәр 2018 елның кышкы чорына җирле әһәмияттә булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тотуга муниципаль контрактлар төзергә;

2017 елның 1 июленә кадәр җирле әһәмияттә булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны билгеләргә, аларның килеп чыгуына китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чараларны алга таба тормышка ашырып;

автомобиль юллары участокларына реконструкция яки ремонт үткәргән урыннарда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

илкүләм стандартлар таләпләре нигезендә, беренче чиратта, белем бирү оешмалары һәм балалар бакчалары янында җәяүлеләр хәрәкәте өчен имин шартлар тудыру буенча өстәмә чаралар күрергә;

суд приставларының территориаль бүлекчәләре белән берлектә, аларга карата мәҗбүри эшләр рәвешендә җаваплылыкка тарту турында суд карары булган затларның хезмәтеннән файдалану урыннарын (участокларын) билгеләргә.

13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар турында» 2015 ел, 29 декабрь, 1002 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

14. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков